СПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КУРАЛОВО ҖИРЛЕГЕ

БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

«24» 09.2020 ел № 19

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Куралово авыл җирлеге Башкарма комитетының 07.05.2020 ел, № 10 карары белән расланган «2020-2023 елларга Куралово авыл җирлеге территориясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү» программасына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 05 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Куралово авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Куралово авыл җирлеге җирлеге Башкарма комитетының 07.05.2020 ел, № 10 карары белән расланган «2020-2023 елларга Куралово авыл җирлеге территориясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү» программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. “Программа бурычлары” бүлекчәсенең җиденче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«-Кече һәм урта эшкуарлык субъектларын муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен сатып алуларда катнашуга җәлеп итү».

1.2. 3нче бүлекнең унберенче абзацын төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Спас муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (htth:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Куралово авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе М.Н.Федотова